# Творческий конкурс “Вперед - в прошлое -2012”



Баулы муниципаль районындагы Исергәп авылы Татарстан Республикасының көньяк көнчыгышында урнашкан. Авылыбыз көньяктан Башкортостан Республикасы белән чикләшә. Чәчү кырлары һәм файдаланыла торган җирләре белән ул 606541 гектар мәйданны били. Бүгенге көндә авылда 421 хуҗалыкта 1096 кеше яши. Табигате бай булган бу җирдә халык бик күптәннән яши. Җиребез чишмәләргә,урманнарга бай.Исергәп сүзе төрек теленнән “Есиркә” (жәлләү) мәгънәсенә ия. Бөрьян башкортларында Исергәп сүзе кеше исеме (Исиркап) буларак кулланыла (“Башкорт шаҗәрәләре” 152 бит).Исергәп исемле башкорт кешесе гаиләсе белән шушы урынга килеп урнаша һәм яши башлый, әле дә булса ул килеп урнашкан урам халык телендә “Башкорт урамы” дип атала. Башкорт кешеләре авылның беренче кешеләре булалар, шулардан чыгып авылның исеме Исергәп дип атала башлый.



***<u>Кәкре күл, Аккош күле, Үрдәк күле,Чучка күле күренешләре</u>***

Бу урыннар кыргый җәнлекләре күп булган урманнарга, сулыкларында төрле балыклар йөзгән күлләргә, елгаларга бай, җирләре дә уңдырышлы балчыклы була.

1761 елның 17 июнендә авылга үзенең якыннары белән Мансур Тавилов килеп урнаша. 1762 елны адмиралтийствога язылган берничә кеше ***<u>Казан</u>*** һәм ***<u>Свияга</u>*** өязеннән килеп төпләнәләр. Казан ягыннан килеп урнашкан кешеләр урамы әле дә булса халык телендә ***Казан урамы*** дип йөртелә.

1918-1919 елны авылда беренче совет мәктәбе ачыла.
1929 елда башлангыч мәктәпкә үзгәртелә.
1935-36 уку елында җидееллык мәктәп оеша.
1958- 59 уку елында мәктәп сигезеллык итеп үзгәртелә.
1966-67 уку елында 320 урынга исәпләнгән яңа мәктәп төзелә һәм урта мәктәп ачыла.
2005 елның 1 сентябрендә 162 урынлы ике этажлы мәктәп ачылды һәм эшли башлады.



***Авылның мәчете, мәктәп, “Карлыгачкай” балалар бакчасы, авыл җирлеге идарәсе, Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар хөрмәтенә ачылган обелиск (Бөек Җиңүнең 20 еллыгына ачыла), Герой ана монументы (Җиңүнең 50 еллыгына ачылды).***



Авылның көньяк-көнбатыштан күренеше.

Авылның көнбатыштан күренеше.

